ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**09.07.2025**

Зеленодольск
шәһәре

**КАРАР**
**№ 1816**

Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 3 декабрендәге 2630 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы бюджетыннан бирелә торган акчалар исәбеннән, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы мәгариф учреждениеләрендә эшләүче педагогик хезмәткәрләргә – яшь белгечләргә айлык стимуллаштыручы өстәмә түләү бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Педагогик хезмәткәрләргә – яшь белгечләргә айлык стимуллаштыручы өстәмә акча билгеләү турында» 2018 елның 29 декабрендәге 1270 номерлы карары белән расланган, Гамәлгә куючы функцияләре һәм вәкаләтләре Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан гамәлгә ашырыла торган ятим балалар һәм ата – ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар өчен дәүләт оешмаларында, гамәлгә куючы функцияләре һәм вәкаләтләре Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, Татарстан Республикасы спорт министрлыгы тарафыннан гамәлгә ашырыла торган дәүләт мәгариф оешмаларында эшләүче педагогик хезмәткәрләргә -яшь белгечләргә ай саен айлык стимуллаштыручы өстәмә акча бирү тәртибенә үзгәреш кертү турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2025 елның 12 маендагы 314 номерлы карары нигезендә, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 3 декабрендәге 2630 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы бюджетыннан бирелә торган акчалар исәбеннән, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы мәгариф учреждениеләрендә эшләүче педагогик хезмәткәрләргә – яшь белгечләргә айлык стимуллаштыручы өстәмә түләү бирү тәртибенә (2021 елның 24 маендагы 1127 номерлы, 2023 елның 07 июнендәге 1696 номерлы карарларна кертелгән үзгәрешләр белән) үзгәрешләрне кертеп 3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Әлеге Тәртиптә педагогик хезмәткәр - яшь белгеч дип төп һөнәри белем бирү программалары һәм (яисә) һөнәри белем бирү программалары буенча укуын тәмамлаган, алган квалификациясе нигезендә беренче тапкыр эшкә урнашучы, шул исәптән төп һөнәри белем бирү программалары һәм (яисә) һөнәри белем бирү

программалары буенча уку чорында алган хезмәт стажы булган яшь белгеч дип 35 яшькә кадәрге Россия Федерациясе гражданы танылa».

2. Әлеге карарны Зеленодольск муниципаль районы Советы аппаратының җәмәгатьчелек, массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтәләр бүлеге начальнигына «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматының рәсми (http://pravo.tatarstan.ru) порталында һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының рәсми (http://zelenodolsk.tatarstan.ru. ) сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары - Мәгариф идарәсе башлыгына йөкләргә.

Җитәкче З.Ф. Хәбибуллин